**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6979**
**23.11.2018**

«Намуслылар буыны» коррупциягә
каршы тематикага эшләрнең шәһәр
конкурсын үткәрү турында

Россия Федерациясе Президентының «2016-2017 елларга коррупциягә каршы тору илкүләм планы турында» 2016 елның 1 апрелендәге 147 нче Указы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34 нче Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015-2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 нче карары, шәһәр Уставының 41 маддәсе нигезендә, Башкарма комитетның 2014 елның 18 ноябрендәге 7047 нче карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын үтәү йөзеннән

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенә 2018 елның декабрендә «Нур» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесендә «Намуслылар буыны» коррупциягә каршы тематикага эшләрнең шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезнамәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурсның оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «Намуслылар буыны» коррупциягә каршы тематикага эшләрнең шәһәр конкурсын оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнарны финанслауны 2018 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлегендә каралган акчалар хисабына 25 000 (егерме биш мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2018 елның 23 ноябрендәге
6979 нчы карарына
1 нче кушымта

«Намуслылар буыны»
коррупциягә каршы тематикага эшләрнең шәһәр конкурсын үткәрү турында
нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Намуслылар буыны» коррупциягә каршы тематикага эшләрнең шәһәр конкурсы (алга таба – конкурс) Башкарма комитетның 2014 елның 18 ноябрендәге 7047 нче карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасы кысаларында үткәрелә.

2. Конкурсның максаты булып шәһәр яшьләре арасында коррупциягә каршы дөньяга карашны пропагандалау тора.

3. Конкурсның бурычлары:

1) коррупцион җинаятьләргә карата тискәре җәмәгатьчелек фикере формалаштыру;

2) коррупция проблемаларын яктыртуга иҗади якын килү (проблеманы яктыртуда нәтиҗәле алымнар һәм методлар куллану);

3) аның барлык төрләре һәм күренешләрендә коррупциягә каршы көрәш темасы буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү күнекмәләре алу;

4) яшьләр мохитендә актив тормыш позициясе тәрбияләү.

4. Конкурсны оештыручы булып Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе тора.

5. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

6. Конкурста һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмаларының көндезге уку формасындагы беренче курс студентлары катнаша ала.

2 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

7. Конкурста катнашу өчен заявка, әлеге нигезнамәгә кушымтада каралган форма буенча, 2018 елның 30 ноябренә кадәр gsschelny@mail.ru электрон почта аша оештыру комитетына бирелә.

8. Конкурс ике этапта үткәрелә:

1) 1 этап – сайлап алу этабы: 2018 елның 30 ноябреннән 5 декабренә кадәр үткәрелә. Әлеге этап кысаларында оештыру комитеты 2 этапта катнашучыларны сайлап ала;

2) 2 этап – турыдан-туры: 2018 елның 7 декабрендә массакүләм мәгълүмат чараларын, студентларны һәм конкурста катнашучыларны чакырып, ачык күрсәтү.

9. Конкурс материалларын тапшыру тәртибе:

1) конкурста катнашучылар, номинацияләр буенча материалларны әлеге нигезнамәдә билгеләнгән срокларда тәкъдим иткән очракта, катнашуга кертелә;

2) оештыру комитетына 2018 елның 30 ноябреннән соң кергән конкурс материаллары каралмый;

3) конкурска җибәрелгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

10. Конкурс материаллары түбәндәге номинацияләр буенча тәкъдим ителә:

1) «Коррупция зарарлы!» темасына картиналар форматында юмористик интернет-мемнар (5 данә).

2) фото-кросс - түбәндәге тематикага фоторәсемнәр:
- «Уку йорты – коррупциясез территория»;
- «Ришвәттән срокка кадәр – бер минутлык эш»;
- «Коррупциясез уку – якты киләчәк»;
- «Бирмәскә – алмаска»;
- «Белемне сатып алып булмый!»;
- «Белем акчадан мөһимрәк»;
- «Ирекле тема».

11. Конкурс материаллары 5 баллы системада түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

1) «Юмористик интернет-мемнар» номинациясе»:
- концептуальлек;
- мәгълүмат тулылыгы;
- юмор;
- үзенчәлеклелек;
- ирония;

2) «Фото-кросс» номинациясе:
- тышкы бизәлешне бәяләү;
- мәгълүмат тулылыгы;
- бирелгән теманың ачылуы;
- креативлык;
- стандарт булмаган якын килү;
- куелыш;
- фоторәсемнәрнең сыйфаты;
- аныклык;
- зурлыгы.

## 3 бүлек. Конкурска йомгак ясау

12. Конкурска йомгак ясау катнашучылар җыйган баллар саны буенча оештыру комитеты тарафыннан башкарыла. Оештыру комитеты карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

13. Конкурста җиңүчеләр дипломнар һәм акчалата призлар белән бүләкләнә. Конкурс йомгаклары буенча оештыру комитеты тарафыннан конкурс эшенең креативлыгы өчен махсус бүләкләр тапшырыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева

«Намуслылар буыны»
коррупциягә каршы тематикага
эшләрнең шәһәр конкурсын
үткәрү турында нигезнамәгә
кушымта

«Намуслылар буыны» коррупциягә каршы тематикага эшләрнең
шәһәр конкурсында катнашуга заявка

Белем бирү оешмасының исеме

| № | Ф.И.А.и. | Номинация |
|---|---|---|
| 1. | | |
| 2. | | |
| 3. | | |
| 4. | | |
| … | | |

Җитәкченең имзасы

Башкарма комитетның
2018 елның 23 ноябрендәге
6979 нчы карарына
2 нче кушымта

«Намуслылар буыны» коррупциягә каршы тематикага эшләрнең
шәһәр конкурсын оештыру комитеты
составы

| Т/с | Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Хафизов Рәсим Рәхимҗан улы | оештыру комитеты рәисе, Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы урынбасары, яшьләр белән эшләү бүлеге башлыгы |
| 2. | Николаева Надежда Григорьевна | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе яшьләр белән эшләү бүлегенең баш белгече |
| 3. | Арушанян Давид Игоревич | «Шәһәр Студентлар Советы» җирле яшьләр иҗтимагый оешмасы рәисе (килешенү буенча) |
| 4. | Трянина Полина Михайловна | Яр Чаллы шәһәренең «Нур» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе директоры |
| 5. | Сироткин Евгений Александрович | Яр Чаллы шәһәренең «Нур» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесенең оештыру-массакүләм эшләр бүлеге мөдире |
| 6. | Мөхәммәтҗанова Римма Равил кызы | Башкарма комитетның икътисадый сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе башлыгы |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2018 елның 23 ноябрендәге
6979 нчы карарына
3 нче кушымта

«Намуслылар буыны» коррупциягә каршы тематикага эшләрнең шәһәр конкурсын оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнар сметасы

<table>
<tr><th>Учреждениенең исеме</th><th>Чыгымнар статьясы</th><th>Сумма (сум)</th></tr>
<tr><td rowspan="2">Яр Чаллы шәһәренең «Нур» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе</td><td>«Юмористик интернет-мемнар» номинациясендә призлар фонды:<br>1 урын – 3000 сум х 1 данә<br>2 урын – 2000 сум х 1 данә<br>3 урын – 1000 сум х 1 данә<br>Махсус приз – 1000 сум х 1 данә<br><br>Иң яхшы «Фото-кросс» номинациясендә призлар фонды:<br>1 урын – 3000 сум х 1 данә<br>2 урын – 2000 сум х 1 данә<br>3 урын – 1000 сум х 1 данә<br>Махсус приз – 1000 сум х 1 данә</td><td>14 000,00</td></tr>
<tr><td>Типография хезмәтләре</td><td>11 000,00</td></tr>
<tr><td colspan="2">барлыгы:</td><td>25 000,00</td></tr>
</table>

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева